ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.04.2021 п.г.т.Алексеевское № 149

**Торак урыны мәйданының исәп-хисап нормасы һәм социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны мәйданын бирү нормасы турында**

Россия Федерациясе Торак кодексының 50, 58 маддәләрен гамәлгә ашыру, дәүләт торак программаларын гамәлгә ашыру максатларында

**карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында торак урын мәйданының исәпкә алу нормасын билгеләргә, шуннан чыгып, гражданнарны торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәпкә алу максатларында аларның торак урынының гомуми мәйданы гаиләнең бер әгъзасына 18 кв. метрдан артмаган күләмдә торак урын белән тәэмин итү дәрәҗәсе билгеләнә.
2. Социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннар белән тәэмин ителешнең ирешелгән дәрәҗәсеннән чыгып, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында бер гражданга торак урынның гомуми мәйданының 18 кв. метр күләмендә торак урын бирү нормасын билгеләргә.
3. Торак урынның гомуми мәйданын бирү нормасын арттыру Россия Федерациясе Торак кодексында каралган очракларда рөхсәт ителә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **О.А.Гайнуллин**